**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КРАСНОСЕЛЬСКИЙ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422700, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Биектау тимер юл станциясе поселогы, Совет ур., 13

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КРАСНОСЕЛЬСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422700, Республика Татарстан, Высокогорский район,
п. ж/д ст. Высокая Гора, ул. Советская, 13

**тел./факс 8(84365) 2-35-82, e-mail: Ksel.Vsg@tatar.ru**

---

**КАРАР
30 декабрь 2021 ел**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ
№ 19**

## Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлегенен бюджет керемнәренең 2022 елга һәм 2023-2024 елларның план чорына баш администраторлары исемлеген раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының $160^{1}$ статьясындагы $3^{2}$ пунктының өченче абзацы, шулай ук «Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органнарына (дәүләт органнарына), җирле үзидарә органнарына, җирле администрация органнарына бюджет керемнәренең баш администраторы вәкаләтләрен беркетүгә һәм Россия Федерациясе субъекты бюджеты, Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген раслауга карата гомуми таләпләрне раслау турында 2021 елның 16 сентябрендәге 1569 нче номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән билгеләнгән тәртипт нигезендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ**:

1. Кушымтатда бирелгән Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге бюджет керемнәренең баш администраторлары исемлеген расларга.
2. Әлеге карар Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлегенең 2022 ел бюджетыннан башлап һәм 2023, 2024 елларның план чорына (2022 елга) бюджетын төзегәндә һәм үтәгәндә барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» Интернет-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
4. Карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Красносельский авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе И.З. Газизов

1 нче кушымта

«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге бюджет керемнәренең 2022 елга һәм 2023-2024 елларның план чорына баш администраторлары исемлеген раслау турында» гы Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 елның 30 декабрендәге 19 нче номерлы карарына

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге бюджет керемнәренең 2022 елга һәм 2023-2024 елларның план чорына җирле үзидарә органнарына беркетелгән администраторлары**

| Бүлек коды | Бюджет классификациясе коды | Төркемнәрнең, төркемчәләрнең, статьяларның һәм ярдәмче статьяларының керемнәрнең исеме |
|---|---|---|
| 904 | Биектау муниципаль районының финанс-бюджет палатасы | |
| 904 | 1 08 04020 01 1000 110 | Россия Федерациясе закон актлары нигезендә нотариаль гамәлләр кылуга вәкаләтле җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затлары тарафыннан нотариаль гамәлләр кылган өчен дәүләт пошлинасы |
| 904 | 1 08 04020 01 4000 110 | Россия Федерациясе закон актлары нигезендә нотариаль гамәлләр кылуга вәкаләтле җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затлары тарафыннан нотариаль гамәлләр кылган өчен дәүләт пошлинасы |
| 904 | 1 13 01995 10 0000 130 | Авыл җирлекләре бюджетлары акчаларын алучылар тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтүдән (эшләр башкарудан) бүтән керемнәр |
| 904 | 1 13 02065 10 0000 130 | Авыл җирлекләре мөлкәтен эксплуатацияләүгә бәйле чыгымнарны каплау тәртибендә керә торган керемнәр |
| 904 | 1 13 02995 10 0000 130 | Авыл җирлекләре бюджетларының чыгымнарын компенсацияләүдән башка керемнәр |
| 904 | 1 13 03050 10 0000 130 | Җирлекләр бюджеты акчаларын алучылар тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтүдән һәм җирлекләр бюджетларының чыгымнарын |

| | | |
|---|---|---|
| | | компенсацияләүдән башка керемнәр |
| 904 | 1 16 10123 01 010 140 | 2020 елның 1 гыйнварына кадәр барлыкка килгән бурычларны түләү исәбенә керә торган, 2019 елда гамәлдә булган нормативлар буенча муниципаль берәмлек бюджетына күчерелергә тиешле акчалата түләтүләрдән (штрафлардан) керемнәр (муниципаль юл фондын формалаштыруга җибәрелә торган керемнәрдән, шулай ук бурычларны аерым исәпкә алу турында муниципаль берәмлекнең финанс органы карары кабул иткән очракта, бүтән түләүләрдән тыш) |
| 904 | 1 16 10031 10 0000 140 | Авыл җирлеге бюджеты акчаларын алучылар иминият очраклары килеп туган очракта зыянны каплау |
| 904 | 1 16 10061 10 0000 140 | Авыл җирлегенең муниципаль органы (муниципаль казна учреждениесе) белән муниципаль контракт (муниципаль юл фонды акчалары исәбеннән финанслана торган муниципаль контракттан тыш)төзүдән читләштерелгән чыгымнарны каплау максатларында түләүләр |
| 904 | 1 16 02020 02 0000 140 | Муниципаль хокукый актларны бозган өчен Россия Федерациясе субъектлары законнарында билгеләнгән административ штрафлар |
| 904 | 1 16 07090 10 0000 140 | Муниципаль орган, (муниципаль казна учреждениесе) авыл җирлеге алдындагы йөкләмәләрне үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән очракта, закон яки килешү нигезендә түләнгән башка штрафлар, неустойка, пенялар; |
| 904 | 1 17 01050 10 0000 180 | Авыл җирлекләре бюджетларына күчерелә торган ачыкланмаган керемнәр |
| 904 | 1 17 05050 10 0000 180 | Авыл җирлеге бюджетына күчерелә торган башка салым булмаган керемнәр |
| 904 | 1 17 14030 10 0000 150 | Җирлек бюджетларына күчерелә торган үзара салым акчалары |
| 904 | 2 02 15001 10 0000 150 | Дотация бюджетларына җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә |
| 904 | 2 02 16001 10 0000 150 | Муниципаль районнар бюджетларыннан бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә авыл җирлекләре бюджетларына дотацияләр |
| 904 | 2 02 15002 10 0000 150 | Бюджетларның балансслылыгын тәэмин итү буенча чараларга ярдәм итү өчен авыл җирлекләре бюджетларына дотацияләр |

| | | |
|---|---|---|
| 904 | 2 02 29900 10 0000 150 | Җирле бюджетлардан авыл җирлекләре бюджетларына субсидияләр |
| 904 | 2 02 35930 10 0000 150 | Граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу өчен авыл җирлекләре бюджетларына субвенцияләр |
| 904 | 2 02 29999 10 0000 150 | Җирлек бюджетларына башка субсидияләр |
| 904 | 2 02 35118 10 0000 150 | Хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру өчен җирлекләр бюджетларына субвенцияләр |
| 904 | 2 02 30024 10 0000 150 | Россия Федерациясе субъектлары тарафыннан тапшырыла торган вәкаләтләрне үтәү өчен җирлекләр бюджетларына субвенцияләр |
| 904 | 2 02 45160 10 0000 150 | Башка дәрәҗәдәге хакимият органнары кабул иткән карарлар нәтиҗәсендә барлыкка килгән өстәмә чыгымнарны компенсацияләү өчен җирлекләр бюджетларына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар |
| 904 | 2 02 40014 10 0000 150 | Межбюджетные трансферты, передаваемые бюджетам сельских поселений из бюджетов муниципальных районов на осуществление части полномочий по решению вопросов местного значения в соответствии с заключенными соглашениями |
| 904 | 2 03 05030 10 0000 150 | Төзелгән килешүләр нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләр өлешен гамәлгә ашыру өчен муниципаль районнар бюджетларыннан авыл җирлекләре бюджетларына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар |
| 904 | 2 03 05040 10 0000 150 | Торак-коммуналь хуҗалыкны үзгәртеп коруга ярдәм итү фонды дәүләт корпорациясеннән авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча чараларны тәэмин итү өчен җирлекләр бюджетларына кире кайтарылмый торган акчалар |
| 904 | 2 04 05010 10 0000 150 | Дәүләтнеке булмаган оешмаларга авыл җирлекләре бюджетларыннан акча алу өчен грантлар бирү |
| 904 | 2 04 05020 10 0000 150 | Дәүләтнеке булмаган оешмалар тарафыннан авыл җирлекләре бюджетлары акчаларын алучыларга бирелә торган акчалата иганәләрдән керемнәр |
| 904 | 2 03 05099 10 0000 150 | Дәүләт (муниципаль) оешмаларыннан авыл җирлекләре бюджетларына кире кайтарылмый торган башка акчалар |
| 904 | 2 07 05020 10 0000 150 | Физик затлар тарафыннан авыл җирлекләре бюджетларыннан акча алучыларга бирелә торган акчадан кергән акчалардан керемнәр |

| | | |
|---|---|---|
| 904 | 2 03 05020 10 0000 150 | Дәүләт (муниципаль) оешмалары тарафыннан авыл җирлекләре бюджетлары акчаларын алучыларга бирелә торган акчалата иганәләрдән керемнәр |
| 904 | 2 07 05030 10 0000 150 | Авыл җирлекләре бюджетларына кире кайтарылмый торган башка акчалар |
| 904 | 2 08 05000 10 0000 150 | Артык түләнгән яки артык алынган салым суммасы, җыемнар һәм башка түләүләр суммаларын кире кайтару (зачет) өчен, шулай ук мондый кире кайтаруны вакытында башкармаган өчен процентлар суммасы һәм артык алынган суммаларга исәпләнгән процентлар суммасы авыл җирлекләре бюджетларыннан (җирлекләр бюджетларына) күчерелгән. |
| 904 | 2 19 60010 01 0000 150 | Максатчан билгеләнеше булган башка субсидияләрнең, субвенцияләрнең һәм башка бюджетара трансфертларның калдыкларын авыл җирлекләре бюджетларыннан кире кайтару |
| 905 | Биектау муниципаль районының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы | |
| 905 | 1 11 05035 10 0000 120 | Җирлекләрнең идарә органнары һәм алар төзегән учреждениеләрне (муниципаль автоном учреждениеләр мөлкәтеннән тыш)арендага бирүдән кергән керемнәр |
| 905 | 1 14 02052 10 0000 410 | Җирлекләрнең идарә органнары (муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләр мөлкәтеннән тыш) карамагындагы учреждениеләрнең оператив идарәсендәге мөлкәтне сатудан алынган керемнәр күрсәтелгән мөлкәт буенча төп чараларны гамәлгә ашыру өлешендә |
| 905 | 1 14 02053 10 0000 410 | Җирлекләр милкендә булган бүтән мөлкәтне (муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләр, шулай ук муниципаль унитар предприятиеләр, шул исәптән казна предприятиеләре мөлкәтеннән тыш) сатудан керемнәр, күрсәтелгән мөлкәт буенча төп чараларны гамәлгә ашыру өлешендә |
| 905 | 1 11 05025 10 0000 120 | Аренда түләве рәвешендә алына торган керемнәр, шулай ук авыл җирлекләре милкендә булган җирләр өчен аренда шартнамәләрен төзүгә хокук сатудан алынган акчалар (муниципаль бюджет һәм Автоном учреждениеләрнең җир кишәрлекләреннән тыш) |

| | | |
|---|---|---|
| 905 | 1 11 05325 10 0000 120 | Авыл җирлекләре милкендәге җир кишәрлекләренә карата авыл җирлекләре җирле үзидарә органнары, дәүләт яки муниципаль предприятиеләр йә дәүләт яки муниципаль учреждениеләр тарафыннан төзелгән сервитутны билгеләү турында килешүләр буенча түләү |
| 905 | 1 14 06025 10 0000 430 | Авыл җирлекләре милкендәге җир кишәрлекләрен сатудан керемнәр (муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләрдән тыш) |
| 905 | 1 14 06325 10 0000 430 | Авыл җирлекләре милкендә булган җир кишәрлекләрен яңадан бүлү нәтиҗәсендә, шәхси милектәге җир кишәрлекләре мәйданын арттыру өчен түләү |